# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Шушмабаш авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

**“15” ноябрь 2023ел** **№4**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 15 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены йомгаклау беркетмәсе төзелде:

“Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Шушмабаш авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 325 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 70 яшьтән узган гражданнардан тыш, 650 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Шушмабаш авылы Яшьләр урамында юл-урам челтәренең юл полотносында чокырларны ремонтлау;
- Шушмабаш авылында Мәктәп урамына балалар мәйданчыгы сатып алу;
- Шушмабаш авылында урам яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән 20 данә яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру;
- Шушмабаш авылы Төньяк урамында сууткәргеч челтәрен алыштыру;
- Шушмабаш авылындагы зират территориясеннән агачларны санитар кисү һәм чыгару;
- Шушмабаш авылы зиратына 1941-1945 елларда Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарга мемориаль такта ясау һәм урнаштыру?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.»

Халык җыены нәтиҗәләре турында йомгаклау беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 691 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 362 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 362 кеше тавыш бирде; “Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Шушмабаш авылында халык җыенын булып узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре дөрес.

2. “Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Шушмабаш авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 325 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 70 яшьтән узган гражданнардан тыш, 650 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Шушмабаш авылы Яшьләр урамында юл-урам челтәренең юл полотносында чокырларны ремонтлау;
- Шушмабаш авылында Мәктәп урамына балалар мәйданчыгы сатып алу;
- Шушмабаш авылында урам яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән 20 данә яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру;
- Шушмабаш авылы Төньяк урамында сууткәргеч челтәрен алыштыру;
- Шушмабаш авылындагы зират территориясеннән агачларны санитар кисү һәм чыгару;
- Шушмабаш авылы зиратына 1941-1945 елларда Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарга мемориаль такта ясау һәм урнаштыру?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.”

3. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Шушмабаш авылы, Мәктәп урамы, 1б йорт, Мәктәп урамы, 8 йорт, Мәктәп урамы, 5 йорт адреслары буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Арча муниципаль районы Шушмабаш
авыл җирлеге башлыгы В.В.Сәгыйтов